ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында” Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында” 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (2005 елның 26 маендагы 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 5; 2009, № 6; 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 1 – 2), бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“яшьләр арасында милли һәм конфессиональ нигездә дискриминация, көч куллану, расачылык һәм экстремистлык чагылышларын, башка социаль тискәре күренешләрне профилактикалау чараларын гамәлгә ашыру, шул исәптән хокук тәртибен саклау буенча яшьләр отрядлары катнашында;”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 елның 9 июле
№ 55-ТРЗ